# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статьи 42 и 43 Семейного кодекса Республики Татарстан**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
22 февраля 2023 года

**Статья 1**

Внести в Семейный кодекс Республики Татарстан (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 1, № 12 (I часть); 2010, № 12 (II часть); 2011, № 9 (I часть); 2012, № 6 (I часть); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II часть); 2015, № 7 (I часть), № 10 (I часть); 2016, № 5; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 52 (часть I); 2018, № 22 (часть I), № 92 (часть I); 2019, № 60 (часть I); 2020, № 26 (часть I); 2021, № 36 (часть I), № 77 (часть I); 2022, № 83 (часть I); 2023, № 3 (часть I), № 11 (часть I) следующие изменения:

1) в статье 42:

а) в части 5 слова «и давшие» заменить словами «, если одно из них или оба являются гражданами Российской Федерации на момент заключения договора о вынашивании и рождении ребенка (далее – договор о суррогатном материнстве), или одинокая женщина, имеющая гражданство Российской Федерации на момент заключения договора о суррогатном материнстве, давшие», слова «его вынашивания» заменить словами «вынашивания и рождения ребенка»;

б) дополнить частями 6 и 7 следующего содержания:

«6. Лица, указанные в части 5 настоящей статьи, давшие свое согласие в письменной форме на имплантацию эмбриона другой женщине в целях вынашивания и рождения ребенка, могут быть записаны родителями ребенка только с согласия женщины, родившей ребенка (суррогатной матери), также в случаях, установленных пунктом 5 статьи 51 Семейного кодекса Российской Федерации.

7. Лица, состоявшие в браке, указанные в части 5 настоящей статьи, брак которых был прекращен или признан недействительным (за исключением случая, если один из супругов умер) на момент записи родителями ребенка в книге записей рождений, могут быть записаны родителями ребенка только с согласия женщины,

родившей ребенка (суррогатной матери), на основании решения суда и при условии, если судом не будет установлено, что указанный брак был зарегистрирован в целях заключения договора о суррогатном материнстве без намерения создать семью. Суд признает за супругом, права которого нарушены заключением такого брака (добросовестным супругом), право быть записанным родителем ребенка.»;

2) часть 4 статьи 43 после слова «Супруги» дополнить словами «или одинокая женщина».

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

2. Положения частей 5 – 7 статьи 42 Семейного кодекса Республики Татарстан (в редакции настоящего Закона) в части обязательного условия наличия зарегистрированного брака, а также гражданства Российской Федерации у одного из потенциальных родителей, либо у одинокой женщины, либо у суррогатной матери не применяются в отношении случаев, если суррогатная мать по состоянию на 19 декабря 2022 года уже вынашивала ребенка в соответствии с договором, указанным в части 9 статьи 55 Федерального закона от 21 ноября 2011 года № 323-ФЗ «Об основах охраны здоровья граждан в Российской Федерации» (в редакции, действовавшей до 19 декабря 2022 года), заключенным с потенциальными родителями либо с одинокой женщиной, либо родила ребенка в соответствии с указанным договором.

Глава (Раис)
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
09 марта 2023 года
№ 9-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 42 һәм 43 статьяларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 22 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 42 статьяда:
а) 5 өлештә «Үзара никахта торучы һәм баланы күтәрү өчен эмбрионны башка хатынга имплантацияләргә язма рәвештә ризалык бирүче затлар» сүзләрен «Баланы күтәрү һәм тудыру максатларында эмбрионны башка хатынга имплантацияләргә язма рәвештә ризалык бирүче үзара никахта торучы затлар, әгәр аларның берсе яисә икесе дә баланы күтәрү һәм тудыру турында шартнамә (алга таба – суррогат ана турында шартнамә) төзегән вакытка Россия Федерациясе гражданнары булып торса, яисә суррогат ана турында шартнамә төзегән вакытка Россия Федерациясе гражданлыгы булган ялгыз хатын» сүзләренә алмаштырырга;
б) түбәндәге эчтәлекле 6 һәм 7 өлешләр өстәргә:
«6. Баланы күтәрү һәм тудыру максатларында эмбрионны башка хатынга имплантацияләргә язма рәвештә ризалык бирүче әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән затлар баланы тудырган хатын (суррогат ана) ризалыгы белән генә, шулай ук Россия Федерациясе Гаилә кодексының 51 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән очракларда баланың ата-анасы булып язылырга мөмкин.
7. Әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән үзара никахта торучы затлар, бала тууны рәсмиләштерү кенәгәсендә баланың ата-анасы булып язылу вакытына аларның никахлары өзелгән яисә дөрес түгел дип танылган булса (ир йә хатынның берсе үлгән очрактан тыш), суд карары нигезендә һәм суд тарафыннан әлеге никах

гаилә төзү ниятеннән башка бары тик суррогат ана турындагы шартнамә төзү максатларында гына теркәлгән дип танылмаса, баланы тудырган хатын (суррогат ана) ризалыгы белән генә баланың ата-анасы булып язылырга мөмкин. Суд мондый никах төзелү нәтиҗәсендә хокуклары бозылган ир йә хатынның (намуслы ир йә хатынның) баланың ата-анасы булып языла алу хокукын таный.»;

2) 43 статьяның 4 өлешендә «ир һәм хатын» сүзләреннән соң «яисә ялгыз хатын» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 42 статьясындагы 5 – 7 өлешләре нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) теркәлгән никах булу, шулай ук потенциаль ата-ананың берсенең йә ялгыз хатынның, йә суррогат ананың Россия Федерациясе гражданлыгы булу турындагы мәҗбүри шарт өлешендә суррогат ананың 2022 елның 19 декабренә торышына инде «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның (2022 елның 19 декабренә кадәр гамәлдә булган редакциядә) 55 статьясындагы 9 өлешендә күрсәтелгән потенциаль ата-ана йә ялгыз хатын белән төзелгән шартнамә нигезендә бала күтәрүе йә күрсәтелгән шартнамә нигезендә баланы тудыруы очракларына кагылмый.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 09 март
№ 9-ТРЗ